ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов суд районы буенча 3 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. “2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. “2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында” 500-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
5. “Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 494-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. “Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 473-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 519-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. “Татарстан Республикасы законнары җыелмасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 520-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 515-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 518-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. “Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 521-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. “Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 510-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. “Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында” 512-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 507-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. 2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.

16. “Концессия килешүләре турында” Федераль законның 40 статьясына үзгәреш кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

17. “Корал турында” Федераль законның 13 һәм 26 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

18. “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәреш кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү

буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

19. “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына инвалидларның федераль реестрына белешмәләр бирү һәм аларны мондый реестрга кертү тәртибен бозган өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 562617-7 номерлы федераль закон проекты турында.

20. Хөкүмәт сәгате: “2016 – 2021 елларга һәм алга таба 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы транспорт комплексын үстерү стратегиясен гамәлгә ашыруны законнар белән тәэмин итү турында”.

21. Төрлесеннән: Татарстан Республикасында җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат.




Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2018 елның 12 ноябре
№ 2552-V ДС